

ГАРАЖ АМНИСТИЯСЕ: эшне нидән башларга?

> 2

КӘГАЗЬ БОТКАСЫ

Укытучылар хисапларның күплегеннән зарлана

> 2

СЫНАЛДЫМ, СЫНМАДЫМ

Рәвгать Сәлахов, язмышка үпкәләргә ярамый, ди

> 4

«ЯШӘРСЕН», ДИЛӘР

Вакцина ясаткан кеше чирне җиңелрәк кичерә

> 4

ВАТАНЫМ ТАТАРСТАН

1918 елның 12 мартыннан бирле чыга | ИҖТИМАГЫЙ-СӘЯСИ ГОМУМТАТАР ГАЗЕТАСЫ | № 143 (28725) | Шимбә | 2 октябрь | 2021 ел

Газета 1968 елда Хезмәт Кызыл Байрагы ордены белән бүләкләнде

www.vatantat.ru /vatanimtatarstan @vatanymtatarstan /vatanimtatarstan

4604609 000131

Көзге чакырылыш

Армия – чын ир-егет булып кайтырга, алдагы тормышка план корырга, үз-үзеңне аңларга өйрәтә торган җирләр-нең берсе. Күптән түгел армиядән кайт-кан баянчы, музыкант Ильяс Фәр-хуллин шулай ди. Мәскәү өлкәсендә Хәрби диңгез флотына буйсынган элемтә гаскәрендә хезмәт иткән ул. «Хәрби хезмәттән күзем ачылып кайт-ты дисәм, ялгыш булмас. Киткәнче дә үз фикерем бар иде. Үз тормышың өчен үзең җаваплы икән дигән фикер канга сеңеп кайтты», – ди Ильяс.

Илдар Мөхәммәтҗанов

БИЛНЕ КЫСЫП БУАР ЧАК

ТАТАРСТАННАН 3 МЕҢЛӘП ЕГЕТ АРМИЯГӘ КИТӘ

Кичә Россиядә көзге чакырылыш башланды. Быел Татарстаннан 3 меңләп егет армия сафларына озатылачак. Россия күләмендә исә 127 мең егет солдатка китәчәк. Хәтерләсәгез, яз көне ил буенча 134 мең егет хәрби хезмәткә алынган иде. Быел республикадан солдатка алынган егетләрнең күбесе (37 процент) Коры җир гаскәрләренә озатылачак, 14 проценты – Россия Эчке эшләр министрлыгының эчке гаскәрләренә, 11 проценты Хәрби диңгез флотында хезмәт итәчәк, 11 проценты – Стратегик билгеләнештәге ракета гаскәрләренә, 10 проценты Хәрби һава көчләренә һәм башка частьларга озатыла. 40лап солдат альтернатив хезмәткә барачак. Югары белемле, фәнни эш белән шөгыльләнгән 10 егет хәрби ротага озатылачак. Көзге чакырылышта армия сафларына алынган егетләрнең беренче төркеме 15 октябрьдән соң юлга чыгачак.

«Үзәк хәрби округ командаларына солдатлар сайлауга аеруча зур игътибар бирелә. Бирегә яхшы әзерлекле, психик сәламәтлеге тотрыклы булган егетләр генә җибәрелә», – диде кичә журналистлар белән очрашуда Татарстанның хәрби комиссары Сергей Погодин. Яшерен-батырын түгел, хәрби җитәкчелек аеруча зур игътибар биргән әлеге частьтан соңгы арада бер-бер артлы хәвефле хәбәрләр килеп кенә тора. Бернинчә көн элек бирегә хезмәт иткән бер солдат үз-үзенә кул салды. Аңа кадәр шушы ук частьтан тагын бер солдат качкан иде. Алдагы көнне генә янәшәдәге урманнан аның мәетен табып алдылар. Баласын армия сафларына озаткан, озатырга җыенган, гомумән, ир бала үстерүче һәр ата-ана мондый хәбәрләрдән соң ут йотып яши.

«Үз малаең армиягә киткәч, яман хәбәрләр гел колакка керә икән ул. Аларны йөрәккә якын алмаска тырышабыз. Барысы да яхшы була күрсен», – ди Арча районының Күпербаш авылында яшәүче Лилия Мөхәммәтҗанова. Аларның уллары Ранил Ростов-на-Дону шәһәрендә хезмәт итә. Программист белгечлеге буенча Арча педагогия көллиятен тәмамлаган егет дипломны яклауга ук үз теләге белән хәрби бурычын үтәргә киткән. «Дипломын әтисе белән икебезнең туган көнебездә яклаячагын белдек. Улыбыз безгә шундый бүләк ясады», – дип искә алды ул көннәрне Лилия ханым.

Көзге чакырылышка багышланган матбугат конференциясендә катнашкан Казан хәрби гарнизоны прокуроры Сергей Баженов бу уңайдан халыкны тынычландырырга ашыкты. «Үзәк хәрби округ буенча проблемалар юк. Һәрхәлдә, безгә хәвефле хәбәрләр килгәне юк. Солдатларыбыз хәрби бурычын намус белән башкара», – дип белдерде ул.

Коронавирус хәрби хезмәткә чакырылыш эшенә дә үзгәрешләр кертте. Башка еллардан аермалы буларак, солдатларның җыелу пунктында «Ачык ишекләр көне» оештырылмаячак. Татарстанның хәрби комиссары исә, бирегә бар да тәртиптә, дип ышандыры. Чакырылыш алдыннан солдатларның җыелу пункты бинасына косметик ремонт ясалган.

– Хәрби хезмәткә китүчеләр арасында ковид йоктыру очраклары кисәтү өчен барысын да эшлибез. Медицина постлары эшли, кулларны антисептик белән чистарту мөмкинлеге тудырылган. Солдатларга битлекләр таратылачак. Алар аны һәр 2–3 сәгать саен алмаштырып торырга тиеш булачак. Температурасы 37дән югарырак булган егетләр хәрби комиссариатка да, җыелу пунктларына да кертелми. Аларны дәвалану өчен кире өйләренә кайтарып җибәрәчәкбез. Бу чакырылышта тулысынча терелеп өлгермәсәләр, алар хәрби хезмәткә киләсе чакырылышта барачак, – дип ачыклык кертте Сергей Погодин.

Җыелу пунктлары белән казармалардагы бүлмәләр көн дәвамында җилләтелә, көненә ике тапкыр дезинфекция ясала икән. Егетләрне хезмәт итәчәк урыннарына илтеп җиткерәчәк поезд вагоннары да зарарсызландырылачак. «Җыелу пунктына килгәнче егетләр коронавируска ПЦР-тест тапшырырга тиеш. Җыелу пунктына килгәч, алар кабат тест тапшырачак. Коронавируска тестлары тискәре булган егетләр генә хәрби хезмәткә озатылачак», – ди Сергей Погодин.

Армия сафларына китүчеләргә елдагыча кәрәзле телефон белән банк карталы да тапшырылачак. Аңа ай саен 2 мең сум күләмендә акча күчереләчәк. Ятимнәр өчен аның күләме 3 мең сумны тәшкил итә. Банк картасына солдатның ата-анасы да акча күчереп тора ала.

Динә ГЫЙЛАҖИЕВА

Хөкүмәттән ярдәм булачак

Россия Хөкүмәте ашлык җитештерүчеләргә ярдәм итү өчен төбәкләргә 10 млрд сумнан артык акча бүлеп бирәчәк. Әлеге акча аграрийларга бодай, арыш, арпа, кукуруз үстерү һәм шуларны сату чыгымнарының яртысын капларга мөмкинлек бирәчәк.

Бу ярдәмнән 62 төбәк файдалана алачак. Хакимият һәр төбәк өчен матди ярдәм суммасын аерым исәпләгән. Бу очракта җитештерелгән продукция күләме дә исәпкә алынган.

Искәртеп үтик: быел җәй эссе килү сәбәпле, Россиянең күп кенә төбәкләрендә бөртекле культуралар уңышы начар булды. Моңа бәйле рәвештә Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов зыян күргән төбәкләргә дәүләт хакимиятеннән ярдәм сорады.

Өлкәннәргә игътибар

Татарстанның күпфункцияле үзәкләренең барлык офисларында да Өлкәннәр көне уңаеннан «Сезнең турыда кайгыртып» акциясе уза. Ул 8 октябрьгә кадәр дәвам итәчәк.

Үзәк белгечләре өлкәннәрне Дәүләт хезмәтләре порталында, Пенсия фонды, Федераль салым хезмәте һәм башка органнарның сайтларында шәхси кабинет ачып, шунда эшләргә өйрәтә. Торак-коммуналь хезмәтләр өчен түләү, электрон талон алу һәм башка мөмкинлекләрдән файдаланырга да ярдәм итәчәкләр. Акция күпфункцияле үзәкләрнең республика буенча эшләүче барлык 60 филиалында да уза.

Ярминкәдә көтәләр

2 октябрьдә Казанда кабат авыл хуҗалыгы ярминкәләре узачак. Сәүдә иртәнге алтыдан көндезге 12гә кадәр барачак. Башкаланың барлык районнарында да 15 мәйданда сәүдә гөрләячәк.

Сүз уңаеннан, ярминкәләр 25 декабрьгә кадәр оештырылачак. Авыл хуҗалыгы продукциясен арзан бәядән республиканың 22 районыннан килгән фермерлар, 20 агрохолдинг, шул исәптән «Майский», «Таттөрлесоюз», «Ак Барс» компанияләре, кошчылык фабрикалары тәкъдим итәчәк.

«Салават күпере» торак комплексында яшәүчеләр сорави буенча, ярминкәләр Осиново бистәсендәге «Радужный» сәүдә үзәгенең парковкасы мәйданында да узачак.

Актуаль тема

Иркенәю нәтиҗәсе

Элеккегеләре үтәлмәсә, яңалары өстәләчәк. Татарстанда коронавирус инфекциясе таралу сәбәпле, яңа чикләүләр кертү хакында уйлана башлаганнар. Хәер, төгәл кararга килү өчен вазгыятьне анализлау кирәк. Әлегә анысы да куандыра торганнардан түгел...

Татарстанда узган тәүлектә коронавирус йоктыручылар саны 63кә җиткән. Республика буенча Роспотребнадзор идарәсе башлыгы Марина Патяшина әйтүенчә, хәзер вазгыять киеренке кала бирә һәм борчуга сала. «Соңгы дүрт атна дәвамында авыручылар саны үсә. Һәр яңа атна саен сырхаулар саны 10 процентка күбрәк теркәлә», – диде идарә башлыгы.

Моңа өстәп кискен респиратор вирус авыручылар йоктыручылар да арта. Бер атна эчендә Татарстанда шундый 27 мең очрак теркәлгән.

Кискенләшкән вазгыять яңа чикләү чараларын кертүгә этәрмәсме? Марина Патяшина да, бу хакта уйлыйбыз, ди.

– Бу хакта фикер алышабыз. Киләсе атнада билгеле булыр дип уйлыйм. Атналык вазгыятькә тулы анализ кирәк әле. Кемнәр күбрәк авырый, шуларны ачыклыйсы бар, – диде идарә башлыгы. – Бездә массакүләм чараларда катнашучы кешеләр саны чикләнгән, бина эчендә – 100, тышта 200дән кеше булырга мөмкин. Хәзерге вазгыять исә андый чараларны үткәрүне күчереп торуны таләп итә.

Замана зәхмәтенә каршы вакцина ясату мәсьәләсенә килгәндә, белгечләр аның акрын баруына борчыла.

– Узган елның сентябре белән быелгысын чагыштырсак, кагыйдә бозучылар саны 2,5 тапкыр артты. Иркенәйдек, арыдык дигәннәре шушыдыр инде. Тик бу иркенәю борчуга сала, чөнки вакцина ясатучылар аз, – диде Марина Патяшина. Идарә башлыгы студентлар арасында – нибары 21, хезмәт күрсәтү өлкәсендә эшләүчеләрнең 23 проценты гына прививка ясатуын белдерде. Мәгариф, социаль, медицина тармагында эшләүчеләрнең коллектив иммунитеты исә – 60–80 процент.

Татарстан буенча коронавируска каршы вакцина ясатучылар саны 1084698 кешене тәшкил итә. Икенче дозаны 953968 кеше алган. Кабат вакцина ясатучылар саны – 14 меңләп. Татарстанның сәламәтлек саклау министры урынбасары Владимир Жаворонков, бу күрсәткеч бик кечкенә, ди.

– Әгәр сез гыйнвар – февраль айларында бер тапкыр прививка ясаткан булсагыз, аны кабат ясату турында уйларга кирәк. Үз тәҗрибәгездә вакцинаның нәтиҗәлелеген күргәнгә, зыян китермәвенә инандыгыз бит, – диде ул.

Министр урынбасары сәламәтлек саклау тармагы җитәкчеләренә тәшкән йөкнең дә зур булуын әйтте. Эш бер минутка да тукталмый. Медицина хезмәткәрләре кулыннан килгәнен барысын да эшли. Республика буенча ятаклар саны җитәрлек күләмдә, запас бар», – диде Владимир Жаворонков.

Иркенлек тою җаваплылыкны киметергә тиеш түгел. Министр урынбасары шундый фикердә һәм халыкны аң булырга чакыра.

– Коронавирус белән яшәргә күнегү – ул әле уяулыкны киметү түгел, ә тормышка яңа гадәтләр кертү дигән сүз. Шул ук битлек кию, социаль дистанция саклау, – диде Владимир Жаворонков.

Теманың дәвамы 4 нче биттә >

Татармын! Горурмын!

Дамир ИСХАКОВ, галим, тарихчы:

Әлегә без Россиядә сан ягыннан икенче урында торабыз. «Без монда күп һәм көчле, чөнки биредә элек-электән руслар белән мөнәсәбәттә булганбыз, үзебезнең тарихи урыныбыз бар», – дип тә әйтә алабыз. Ул – безнең статусны күтәрә торган әйбер. Шуңа күрә җанисәп вакытында һәр кеше нык итеп уйларга тиеш. Минемчә, катнаш никахта булган кешеләр дә татар булып язылырга, шул якка каерыга тиеш.

(«Интертат» электрон газетасына әңгәмәсеннән)

КҮПМЕ АКЧА ЯҢА КАЛА?

Россиядә яшәүчеләр соңгы елларда ешрак һәм күбрәк акчасын яңа калдыра башлаган. «Работа.ру» хезмәте халыкның нәрсә өчен һәм күпме күләмдә акчасын яңа калдыруы хакында белешкән.

НИЧӘ СУМ ЯҢА КАЛДЫРАЛАР?

1 мең сум.........30%	5–6 мең сум.....21%
3 мең сум.........27%	10 мең сум.......9%

НӘРСӘДӘН БАШ ТАРТАЛАР?

Кием-салым, аяк киеме сатып алу	58%
Кафе, күңел ачу урыннарына йөрү	20%
Таксида йөрү, өйгә ризык китерү	33%

Яшелчә бәясе төшкән

Татарстанстат мәгълүматлары буенча, республикада кайбер яшелчәләргә бәя төшкән. Шулар арасында суган, кәбестә, кишер бар. Ә менә бәрәңгегә бәя арткан. Суганның килосы 31,84 сум тора. Кишер – 35,88, кәбестә – 36,73 сум. Бәрәңге бәясенә килгәндә, аның килосы 33,31 сумга җиткән.

Шул ук вакытта тавык итенә бәя 1,45 процентка артып, килосы 156,71 сумга җиткән. Йомыркага бәя 4,79 процентка арткан һәм дистәсенә 50,83 сумны тәшкил иткән.

Татарстан Авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министрлыгы белдергәнчә, хәзерге вакытта яшелчәләргә бәя тотрыкланган. Шулар арада бәрәңгегә бәйле сизелерлек үзгәрмәскә тиеш. «Алга таба әлеге төр продукциягә бәя арту сезонлы үзгәрешләргә бәйле булачак. Кайберләренең бәясе кисәк кенә арту инфляциядән алдарак булды. Бу хәл Россиянең барлык төбәкләрендә дә күзәтелде», – дип хәбәр итә министрлыкның матбугат хезмәте.

ЖИДЕНЧЕ КАТТАН КАРАШ

Наил ШӘРИФУЛЛИН

Без нигә фәкыйрь?

Россия Президенты илнең төп дошманы дип фәкыйрьлекне атады. Олы территориягә, андагы хисапсыз байлыкларга ия булып та, ник без һаман да фәкыйрь соң? Ихтимал, Россия артык үзенчәлекле, башкаларга охшамаган ил булгангадыр. XXI гасырда да көчкә очны очка ялгаучылар күплеге, илнең шундый дәүләтләр сафын тулыландырып тору сәбәпләре, әлбәттә, күп төрле. Алар объектив һәм субъектив, бер-берсенә күпмедер бәйле. Тарихка барып тоташканнары да юк түгел. Шул сәбәпләрнең үзем электән мыекка чорнап куйган, күргән-белгәннәренә тукталасы, анализлыйсы килә.

Беренчедән. Россиянең иксез-чиксез киңлекләре, территориясенең зурлыгы халыкның тормыш дәрәҗәсен, аңын үстерүдә һәрчак тискәре роль уйнап килде. Территориаль зурлык яхшы юллар, төзек коммуникацияләр сорый. Алар аз. Һаман да Гогольча, һаман да ике бәла – «Дороги и дураки» ук булмаса да, юллар да, булган коммуникацияләр дә XXI гасыр таләпләренә җавап бирми. Яхшыны төзер, булган тиклесен төзек тотар өчен тотрыклы икътисадка, үсешкә ия булу, эчке каршылыкларсыз яшәү, булдыклылык кирәк. Алары да биредә җитми.

Ара ераклыгы идарә итүне дә, аралашуны да кыенлаштыра. Элек-электән рус җирләренә цивилизация казанышлары – мәгърифәт, алдынгы фикер, мәдәният, ара ерак, халык таркау, берәнсәрән яшәгәнлектән, багланышлар сыек булганлыктан, эчкә начар үткән. Күп кенә яңарышлар төбәкләргә бөтенләй дә барып җитмәгән. Зурлык димәктән, мәшһүр «шестидесятник» Евгений Евтушенко Россияне озын койрыклы, шул койрыгы, гәүдәсе башыннан ерак, аерым яшәүче галәмәт олы түшкәле, кечкенә башлы динозавр белән чагыштырган иде…

Икенчедән. Россиянең чиксез киңлекләренең күпчелек өлеше, климат ягыннан караганда, рациональ хуҗалык алып бару өчен яраксыз. Җиде-сигез ай буе кыш. Кыска җәй. Кышкы салкын 30–40 градуска җитә. Шуның аркасында Россиянең энергетик чыгымнары ифрат та зур. Санап, очына да чыгарлык түгел. Торакларны, предприятиеләрне җиде-сигез ай буена җылыту өчен күпме ягулык кирәк. Күпме котельныйлар, җылылык трассалары төзү, аларны карап, ремонтлап тору зарур. Салкынга каршы тору өчен нигез-фундаментлар тирән, стеналар калын булу мөһим. Бу инде Көнбатыш Европадагы җил-яңгырдан сакланыр өчен генә салынган, күп дигәндә бер кирпеч калынлыгы диварлар, бер катлы тәрәзәләр түгел. Биредәге салкын безнең көч-энергияне, акчаны, ресурсларны ашап, фәкыйрьлегебезне арттырып тора.

Өченчедән. Тагын бер сәбәп: без – материк халкы. Элек-электән алгарыш, цивилизация күбесенчә диңгез яны, диңгез буе илләрендә үскән һәм формалашкан. Флот төзеп, Европага «тәрәзә»не дә Россия XVIII гасырда гына ачты. Диңгез буе халыклары, башкаларга караганда, чит илләр белән күбрәк аралаша. Сәүдә, кораб төзү, бер-берендәге яңалыкларны күреп алып, үзеңдә куллану, диңгез һәм сәүдә белән бәйле алдынгы һөнәрчелек – болар барысы да ул илләрдәге халыкларны башны һәм кулларны яхшырак эшләтергә, һушлы булырга өйрәткән. Ә материк эчендәгеләр күп вакыт изоляциядә кала килгән. Аралашу, тәҗрибә уртаклашу, техника, технология җитмәгән. Бу – безнең фәкыйрьлекнең состав өлеше булган караңгылыкның янә дә бер сәбәбе. Изоляция бүген дә дәвам итә: санкция-чикләүләр аркасында безгә технологияләр сатмыйлар, кредитлар бирмиләр, инвестицияләр күтәреп кермиләр.

Дүртенчедән. Россия киңлекләренең табигый ресурсларга, файдалы казылмаларга бик бай булуы. Әйе, әйе, табигый байлыклар да – безнең бәхетсезлек чыганагы. Биредә Аллаһы Тәгалә биргән шул байлыкны уңга-сулга сатып, шулар хисабына, паразитларча димим, хөрәсән ялкауларча көн күрергә өйрәнелгән. Булдыксызлар һәм сансызлар шөгыле бу. Аллаһы биргәнне сатар өчен олы акыл кирәкми. Ә менә шул ук японнар кебек, бернинди ресурсларсыз җитештерүдә дөньякүләм уңышларга ирешү өчен, югары технологияләр уйлап табу һәм эшләтеп җибәрү, аларны сату, фәнне үстерү өчен ярыйсы гына тирләү, һәрчак тонуста булу мәслихәт. Без биредә аңа өйрәнмәгән. Социализм чоры булсын, хәзер булсын – нефть, газ, руда, урман һ.б. читкә һаман ага тора. Күпме шулай яшәп була?

Әгәр дә без табигый ресурсларга ярлы булсак, ачка үлмәс өчен, чарасызлыктан булса да, нидер җитештерергә, уйлап табарга, актив яшәргә өйрәнгән булыр идек. Бүген кая карама – Кытайда эшләнгән товар. Әллә без кытайлар ясаганны ясамаслыкмы? Тик югарыдагылар җитештерү дип артык баш ватмый. Алар, дөнья базарында нефтькә бәя төшмәсә ярар иде, дип төн йокыларын йокламый. Күптән шуңа җиттек, нефтькә бәяләр, прогноз рәвешендә, ел саен илнең еллык бюджетына кертелә. Хәлең, көнең базардагы нефть бәясеннән торгач, икътисад хакында гомумән нидер сөйләп була микән ул?

Бишенче сәбәп. Россиянең бүгенгә кадәр күпмилләтле, ләкин унитар дәүләт булып калуы. Милләтләрне дәүләтле итүче конфедерация түгел, федерация дигәненең дә исеме генә калып бара. Ил алга китсен, бай яшәсен дигәндә, беренче чиратта төбәкләрне бай итү, аларга икътисади һәм сәяси ирек бирү зарур. Аскы ботаклар өстәгеләрен күтәрә, дип юкка гына әйтмиләр. Әмма аскы ботаклар нык булырга тиеш.

КӘГАЗЬ БОТКАСЫ –

УКЫТУЧЫНЫҢ БАШ АВЫРТУЫ

Илдар Мөхәммәтҗанов

Борчыган мәсьәлә

Укытучылар һаман да хисаплар күплегеннән зарлана. Рособрнадзор кәгазь эшенең ни өчен күп булу сәбәпләрен аңлаткан. Мөгаллимнәр әлеге мәшәкатьтән котыла алырмы?

«Новые люди» партиясе рәисе Алексей Нечаев укытучыларның зарларын Владимир Путинга да җиткергән. Хисапларның артуында Рособрнадзорны гаепләп, хәтта әлеге оешманы таратырга тәкъдим иткән ул. Президент исә, идарәне ябарга түгел, эшчәнлеккә үзгәрешләр кертергә кирәк, дигән. Рособрнадзор башлыгы Анзор Музаев әйтүенчә, ведомство, киресенчә, административ эшләрне киметкән.

– Укытучылардан, хисап эше артты, дигән сүзләрне еш ишетәбез. Ләкин безнең административ эшләрнең артуында катнашыбыз юк. Укытучыларның төп зарлары районнар белән бәйле. Нәрсәдер эшләүне сорап, гаризалар нәкъ менә җирлекләрдәге оешмалардан килә. Рособрнадзор аккредитация, лицензия мәсьәләләре белән шөгыльләнә, – дип аңлаткан Анзор Музаев.

Мамадыш районының Усали мәктәбендә рус теле һәм әдәбияты фәннәреннән белем бирүче, Татарстанның атказанган укытучысы Резеда Фазылова белдергәнчә, «кәгазь боткасы» – укытучының баш авыртуы.

– Аны безгә ничә елдан бирле, киметәбез, нибары өч кенә документ калачак, дип вәгъдә итәләр, әмма барысы да сүздә генә. Киресенчә, хисап эше арта гына бара. Кирәк булганнарын үз белдегең белән тутырып барасың. Ә менә социаль челтәрләрдә ниндидер бәйгеләрдә тавыш бирүләр, башкасы өчен вакыт күп китә. Без моңа бик каршы, тик бу укытучыдан гына тора торган әйбер түгел. Киметсәләр, бик яхшы булыр иде. Укытучының укучылар, әти-әниләр белән тәрбия турында сөйләшергә вакыты калмый. Районда укытучыларны бүки урынына куркытып торган Департамент тикшерүе узды. Аңа нинди генә документлар тапшырмадык?! Кая анда укыту, тәрбия?! Ярый, әти-әниләр бик сабыр. Кәгазь эшенең укыту һәм тәрбиягә комачаулый торган яклары күп. Барысы да аңлый, әмма бетерә генә алмыйлар. Эш программасы нигезендә тематик һәм дәрес планы төзибез. Укытучы, закон буенча, өч документ һәм электрон журнал тутырырга тиеш. Менә шулары җиткән, – ди Резеда Фазылова.

Казан мәктәбе укытучысы Ильяс Мөхәммәтҗанов да, «кәгазь боткасы» кимеде, дип әйтсәләр дә, киресенчә, ике тапкыр артты, ди. Аның фикеренчә, хисап тутырып, укытучының укытырга вакыты калмый.

– Мәктәпләрдә иминлек мәсьәләсен көчәйтүләре әйбәт анысы. Әмма укытучыга тагын эш артты. Хәзер әти-әниләрне мәктәпкә кертмиләр. Алар берәр йомыш белән килсә, каршыларга укытучыга төшәсе. Укытучы балаларны ашханәгә озата, аларны табын янына утырта… Укытучының эшен киметү, дәфтәр тикшерү өчен, аның сәркатибе булырга тиеш дип саныйм, – ди ул. – Әйтик, башлангычта рус, инглиз телләре яки башка укытучы өчәр сыйныф укыта, ди. Аңа 100дән артык баланың эшен тикшерергә кирәк дигән сүз бу. Моның өчен дүрт сәгать вакыт китә. Педагогик белеме булган сәркатип бу эшләрдә ярдәм итә алыр иде. Сыйныфта – 35 бала. Атнага бер тапкыр керә торган биология яки башка фәннән бер дәрестә шуның кадәр баладан берничек тә сорап бетереп булмый. Шуңа күрә балалар саны 25тән артмасын иде. Элек физика, химия, биология, география укытучыларының ярдәмчеләре – лаборантлары бар иде. Бу да бетте, бөтенесен дә укытучы үзе эшли. Эш күп, тик хезмәт хакы артмый.

Казан халыкара мәктәбе директоры Нияз Гафиятуллин хисап эшеннән бөтенләй котылып булмый, дип саный.

– Мин 1500 укучы укыган мәктәптә директор булып эшләдем. 120 укытучы бар иде. Сыйныф җитәкчесенең вазыйфасын гына алыйк. Аңа сыйныфындагы барлык укучыларның документларын җыярга, электрон журналны тутырырга, дәрескә әзерләнү өчен план төзергә кирәк. Бу хисап эшеннән котылып булмый. Татарстан мәктәпләре кәгазь эшенә чумган дип әйтә алмыйм. Хисапны тутырыр өчен директор, аның урынбасарлары бар. Система белән мәгълүматсыз идарә итеп булмый, – ди Нияз Гафиятуллин. – Укытучының укытырга вакыты калмавының сәбәбе башкада. Бер ставка – 18 сәгать. Ә педагогка 36–40 сәгать укытырга туры килә. Шуңа күрә аның укытырга, дәрескә яхшылап әзерләнергә вакыты калмый. Әгәр укытучы үзенә тиешле ставкага гына эшләсә, бар нәрсәгә өлгерә алыр иде. Сыйныф җитәкчесенең дә хезмәте гадел бәяләнергә тиеш. Соңгы елда өстәмә акча түләү кертелү яхшы булды.

Сәрия МИФТАХОВА

ПРЕЗИДЕНТ КӨНДӘЛЕГЕ

ТАТАРСТАН ТӘҖРИБӘСЕН ДУБАЙДА ДА БЕЛӘЛӘР

Татарстан Президенты Рөстәм Миңнеханов Берләшкән Гарәп Әмирлекләренә (Дубай) эш сәфәре белән килде. Биредә республика җитәкчесе «Экспо – 2020» Бөтендөнья күргәзмәсендәге Россия павильоны ачылышында катнашты.

Искәртеп узыйк: «Экспо» халыкара күргәзмәсе техник һәм технологик казанышларны күрсәтү өчен мәйданчык булып тора. Бу күргәзмә Дубайда 2022 елның 31 мартына кадәр узачак. Быел ул «Акылны берләштереп, киләчәк төзү» дигән шигарь астында оештырыла.

Күргәзмә ачылышыннан соң Президент «Глобаль мәсьәләләрне хәл итүдә ясалма интеллект куллану» темасына фикер алышуда да катнашты. Аерым алганда, бизнес-проектларда һәм Иннополис университетында ясалма интеллект куллану мөмкинлекләрен тәкъдим иттеләр.

– Республикада Иннополис университеты базасында ясалма интеллект технологияләре өлкәсендә тикшеренүләр алып барыла. Алар күп кенә технологик өлкәләрдә һәм икътисад тармакларында сыйфатлы үзгәрешләргә китерер дип ышанабыз, – диде Президент.

Үз вакытында кадерле

Көзге мәшәкатьләр

Көзге кыр эшләрендәге кимчелекләрне бетерү, хуҗалыкларның матди мөмкинлекләрен арттыру өчен бүген ниләр эшләнә?

Татарстан Премьер-министры урынбасары – авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры Марат Җәббаров әйтүенчә, көзге кыр эшләре вакытында кайбер культуралар, шул исәптән шикәр чөгендере, көнбагыш, бәрәңге, кукуруз һәм яшелчә уңышларын вакытында җыеп алуны төрле сәбәпләр белән тартып-сузып килүче хуҗалыкларның югалтулары бүген дә дәвам итә.

«Әйтик, рапсны соңга калып җыйганда, аның уңышы гектарына 4 центнерга кадәр киму күзәтелә», – ди министр. Бу бит Казан май-экстракт заводы рапсның бер центнерын 5000 сумнан кабул итүен исәпкә алганда, санаулы көннәр эчендә гектарыннан 20 мең сум керем югала дигән сүз! Мондый авыр елда рапс үстерүче хуҗалыкларның 70 миллион сумнан колак кагуы күңелле хәл түгел инде, билгеле.

Кайбер хуҗалыкларның көзге кыр эшләрен вакытында башкарып чыга алулары да икеле. Көзге чәчү буенча планлаштырылган 530 мең гектар мәйданның 100 мең гектары чәчелми калды.

Дөрес, мондый хәлнең үзенә күрә җитди сәбәпләре дә бар. Җәй буена бер тамчы яңгыр күрмәгән җиргә ничек итеп ашлык чәчмәк кирәк? Әмма бүген инде кистереп әйтеп була: көзге кыр эшләрен бераз соңарып булса да тулысынча башкарып чыккан хуҗалыкларның югары уңышка өметләре зуррак.

– Соңгы вакытларда явып узган яңгырлар аеруча сөендерде. Уҗымнар тигез тишелеп, көзге кояшта бераз булса да ныгып калырга өлгерә. Язын тиешенчә тукландырып, вакытында яңгырлар да булса, мул уңышка өмет бар. Һәрхәлдә, 2010 елдагы хәл кабатланмас дип уйлыйбыз, – ди тәҗрибәле агроном, озак еллар Теләче районы авыл хуҗалыгы идарәсе җитәкчесе булып эшләүче Ралиф Низаметдинов.

Көзге кыр эшләренә багышлап, республиканың унбер районында 600дән артык белгеч катнашында узган семинарларда да бу турыда җитди сөйләшүләр булган иде югыйсә. Әмма урыннардан алынган мәгълүматларга караганда, булган кадәр дымны саклап калу буенча хуҗалыкларда хәлләр төрлечә. Планлаштырылган 1 миллион 800 мең гектарның 79 проценты гына эшкәртелгән. Ягъни 400 мең гектарга кимрәк эш башкарылган.

Татарстан авыл хуҗалыгы һәм азык-төлек министры урынбасары Илдус Габдрахманов сүзләренә караганда, көздән эшкәртелгән җир мәйданнарының яртысына якыны гына тирәннән сөрелгән булу да канәгатьләнерлек хәл түгел.

Җирнең өске катламында дымның башка еллар белән чагыштырганда күпкә кимрәк булуын исәпкә алганда, сөрү җирләрен тирәннән эшкәртү быел аеруча зур әһәмияткә ия.

– Кырларда бүген зур егәрлеккә ия булган 1100 техника эшли. Тәүлегенә 63 мең гектар җир эшкәртергә мөмкинлегебез бар. Эшне тиешенчә оештырганда, планлаштырылган мәйданнарны 15 октябрьгә тулысынча тәмамларга уйлыйбыз, – ди министр урынбасары.

Камил СӘГЪДӘТШИН

Илдар Мөхәммәтҗанов

Яңалык

ГАРАЖ АМНИСТИЯСЕ: ӘШНЕ НИДӘН БАШЛАРГА?

2021 елның 1 сентябреннән «Гараж амнистиясе турында»гы Федераль закон үз көченә керде. Гадәттәгечә, баштарак һәр яңалыкның аңлашылып бетмәгән урыннары була. Бу җәһәттән редакциягә укучыларыбыз да шалтырата. Шундый еш очрый торган сорауларның кайберләренә Татарстан Росреестры һәм Кадастр палатасы белгечләреннән җаваплар алдык.

Илдар Мөхәммәтҗанов

➤Гараж милек итеп теркәлгән. Ул урнашкан җир участогын рәсмиләштерү өчен эшне нидән башларга?

Әгәр участок ызанлаштырылмаган булса (бу хакта мәгълүматны башкарма комитеттан алырга мөмкин), беренче чиратта җир чикләренең схемасын әзерләргә кирәк. Моны үзеңә дә эшләргә була, әмма кадастр инженерына мөрәҗәгать итү әйбәтрәк. Аннан җирле үзидарәгә гариза язарга кирәк. Анда исә андый-мондый аңлашылмаучылыклар килеп чыкмаса, җир участогын рәсмиләштерергә дигән карар кабул ителсә, Росреестрга барып торуның кирәге юк. Җирле үзидарә участокны бернинди пошлинасыз үзе рәсмиләштереп бетерәчәк.

➤Безнең гаражлар ике катлы блокларда урнашкан. Икесенә ике кеше хуҗа. Бу очракта яңа закон нигезендә җир участокларын рәсмиләштерергә хокукыбыз бармы?

Юк. Яңа закон буенча бер каттан биегрәк булган гаражлар яки бокслар урнашкан җир участокларын рәсмиләштерү каралмаган, чөнки алар капиталь төзелеш объекты булып санала һәм җирне рәсмиләштерү белән берничек тә бәйле түгел.

➤ Җир участогының чикләре гамәлдәге закон таләпләренә туры китереп билгеләнмәү сәбәпле, гараж һәм ул урнашкан җир участогына почта адресы бирүдән баш тарттылар. Чикләрне билгеләү өчен «гараж амнистиясе» законыннан файдаланырга буламы?

Яңа закон гаражны һәм ул урнашкан җир участогын милек итеп рәсмиләштерергә мөмкинлек бирә. Җир участогының чикләрен һәм конфигурациясен тәгаенләп, ызанлаштыру өчен кадастр инженерына мөрәҗәгать итәргә кирәк.

➤Металл гаражны милек итеп рәсмиләштерергә мөмкинме?

Әгәр гараж күчемсез милеккә кертелә торган объектка туры килмәсә, капиталь корылма була алмый. Димәк, аны рәсмиләштереп тә булмый дигән сүз. Күчемсез милекнең нигезе, стеналары һәм түбәсе булырга тиеш. Гараж үзе дә кирпеч, бетон плитәләр кебек капиталь төзелеш өчен кулланыла торган материаллардан эшләнергә тиеш.

➤Гаражга техник план ясату һәм кадастр үлчәмнәре үткәрү мәҗбүриме? Әгәр гараж кооперативыннан пай түләү турындагы белешмә булса, гараж амнистиясе буенча хокукларны теркәтү срогы күпмегә сузыла?

Әгәр гараж кадастр исәбендә тормаса, техник документлар әзерләү өчен кадастр инженерына мөрәҗәгать итәргә кирәк. Кадастр исәбенә кую һәм милеккә хокукларны теркәү срогы – 12 көн.

➤Әти-әнием 2003 елда күршеләрдән капиталь гараж сатып алганнар иде. Кулдан гына сату-алу турында килешү яздылар. Күршебез дә, әти дә вафат инде. Килешү югалган, әнидә гараж хуҗасы икәнен раслаучы бернинди документ та калмаган. Ул гаражны рәсмиләштерә алырмы икән?

Бу очракта гаражны рәсмиләштерү өчен түбәндәге документлар ярдәм итә ала:

◆ гаражны инженер-техник челтәрләргә тоташтыру турында документ;

◆ коммуналь хезмәтләр күрсәтү турында килешү;

◆ коммуналь хезмәтләргә түләүне раслаучы документ;

◆ 2013 елның 1 гыйнварына кадәр техник инвентарьлаштыру үткәрелгәнне раслаучы документ. Анда гаражның хуҗасы яки документны әзерләргә заказ бирүченең исем-фамилиясе булырга тиеш.

__Исегезгә төшерәбез:__ гараж амнистиясе буенча документларны күчемсез объектлар урнашкан территориядәге җирле үзидарәнең башкарма органнарына тапшырырга кирәк. Казанда бу – район хакимиятләре, районнарда, кагыйдә буларак, Җир һәм милек мөнәсәбәтләре палатасы.

Фәния ӘХМӘТҖАНОВА әзерләде

ҺИЧ ОНЫТАСЫМ ЮК

ХАННА. ХӘМДҮШ. ХӘМДҮНӘ

Күчмә театрга мин 1979 елда эшкә урнаштым. Авылдан-авылга йөреп спектакльләр куябыз. Туган ягым – Саба районының Сатмыш авылына да килеп чыктык. Клуб янына зур афиша эленгән. Габдулла Рәхимкулов белән Хәмдүнә Тимергалиева киләчәк икән. Габдулла абый инде нәрберебезгә дә яхшы таныш, Хәмдүнәсе кем икән? Шунда Исламия апа белән Хәлил абый Мәхмүтовлар аңа бик яхшы бәя бирделәр, исе-без-акылыбыз китеп тыңлап тордык. Аны күрәсе килү, тыңлау теләге уянды.

Мин Батыршин урамындагы 63 нче йортның тулай торагында яши идем. Көннәрдән бер көнне, жырчы Хәмдүнә дә безнең тулай торакта яши икән, дигән хәбәр таралды һәм ул тиз арада үз кеше булып китте. Менә мине тыңлагыз дигән сыман коридорда да, аш бүлмәсендә дә жыр сузып җибәрә, безгә «апаем» дип дәшә, миңа «озын чәч» дигән кушамат та такты. Артист артистны тиз аңлады булса кирәк, безнең фикерләр, серләр килеште. Мин исә аңа, каян башыма килгәндер, Ханна дип дәшә идем. Бу исемне ул ошатты. Тулай торактагыларның күңеленә дә якын булды бу исем. Без аны Олеся Френкельга да охшата идек. Хәмдүнәнең дә чәче үзенә бер төрле – ак та түгел, сары да түгел. Озын буйлы, ябыграк гәүдәле. Ап-ак кофта, ап-ак юбка киеп йөрергә ярата. Иртән иртүк уяна да: «Апаем, чәй кайнады, әйдә чәй эчәргә», – дип чакырып йөри башлый. Коридорда иртән иртүк җырлап йөрүенә дә күнегеп бара идек инде. Мине кайбер тантаналарга, аеруча Сабантуйларда жыгыш ясарга үзе белән ала иде, сиңдә Нәҗия Минкина тавышы дип, үсендерен тә җибәрә. Нәҗиянең ул вакытларда Әлфия апа Авзалова бригадасында эшләгән вакытлары. Тора-бара аңа «Хәмдүш» дип дәшү гадәткә кереп китте, бернинди ризасызлык белдермәде, киресенчә: «Әү-әү, апаем», – дип канәгать елмая иде.

Аның бертуган сеңлесе Әлфинәгә түн тектереп йөрүләре дә күңелгә нык уелган. «Сеңлемне сөендерәсем килә, ул бит әнине тәрбияли», – дип әйтә иде Хәмдүнә. Гомумән, ул туганнарына нык булышты. Бүләкләрне алганда да, монысы җиңгәчәйгә, монысы Азаматка (абыйсының улы), дип тәгаенли иде.

Миңа тора-бара иркенрәк бүлмәле тулай торакка күчү насыйп булды. Хәмдүнә истәлек бүләкләре әзерләгән: пластмасс ләгән, берсе зур, икенчесе кечерәк ике чүмеч һәм дә бик матур рәсемнәр төшерелгән калын тәлинкә.

Аларны Ханна – Хәмдүш – Хәмдүнә истәлеге итеп бүген дә саклыйм һәм кулланам. Яшәү урыннары үзгәргәч тә аралар өзелмәде, кунакка йөрештек.

Хәмдүнә берара Башкортстанда Флорит белән яшәп алды бит инде. Шул вакытта мине, Сабантуйда чыгыш ясарга дип, кунакка чакырдылар. Бардым. Башкортстан табигате белән хозурланырга дип машинада чыгып киттек. Рульдә – Флорит. Мул сулы күл буендагы текә тауга күтәреләбез. Көтмәгәндә-уйламаганда, арткa тәгәри башладык. Арттa исә – күл. Машина тәгәрәпме-тәгәри. Шул мәлдә Хәмдүнә Флоритның аякларын читкә этәрде дә кулларны белән тормозга басты. Флоритка исә «Тизлеккә куй», – дип әмер бирде. Ходайның рәхмәте, машинабыз түбәнгә тәгәрәүдән туктады, Хәмдүнәнең тәвәккәллеге безне фаҗигадән саклап калды.

Яшәештә аңа Илһам Шәриф ныклы таяныч булды, Хәмдүнә апасының һәр гозерен ул җиренә җиткереп үтәде, ижатта да, тормышта да ярдәменнән ташламады. Бергәләп сәхнәгә күтәрелделәр, алар башкарган дуэтлар халык күңеленә лаеклы урынын алды.

Хәмдүнә туры сүзле иде. Фикерен кәнфит кәгазенә төрмичә генә җиткерде, шул гадәте белән ул кайвакыт кыен да ашады, әмма нинди генә халәттә дә чын мәгънәсендә Кеше булып калды.

Әлфия ХӘСӘНОВА,
Татарстанның атказанган артисты

Йодрык кадәрле, йомры гәүдәле...

Без үсмер чакларда карап торган бар ризык – бәрәңге иде. Бакчалар зур, 20–25әр сутый. Һәр хуҗалык, мал кермәсен дип, бакча янәшәсенә 50–60 сантиметр тирәнлектә канау казып куйган. Тик кәҗә малы барыбер җаен табып керә. Аннары, бәбәген генә ашап, бәрәңге үсентеләрен гарипли, имгәтә, һәр хуҗалыкта бер йә ике оя каз, алар да яратты бәрәңгене.

Бәрәңге җирен инде май башында ук көрәк белән казый башлыйлар. Әнкәй, туганнар, абый тезелешеп басып җир казыйлар. Күп вакыт мине дә алып чыгалар иде. «Әйдә, әйдә, бәрәңге ашарга бик яратасың», – дип, кулга көрәк тоттыралар. Миңа 12–13 яшь. Җир тип-тигез, кара балчык. Олыраклар мондый туфрак турында: «Ипигә ягып ашарлык», – дип сөйләшәләр. Бәрәңгене колхоз атлары белән чиратлап утыртыш. Ат башын ушлырак малай тота. Орлыклык бәрәңге салуның да үз хикмәте бар: буразнага иелеп, ак ягын аска каратып саласы. Өеннән иске чиләк күтәреп керәсең. Күзәнәкне хуҗалар бакча башына чыгарып куйган капчыклардан чиләкка бушатып алабыз да, беркадәр ара калдырып, тезелешеп басабыз. Кайбер гаиләләрнең орлык бәрәңгәсе вак, йомры булганда сөенешәбез, чөнки аяк өсте генә ташлап барырга була. Икешәр сәгать иелеп эшләп йөргәндә исә куз аллары әлҗемәлҗе килә.

Бәрәңге утыртышырга кергәндә өйдә ашап тору юк инде, гадәттә эш бик иртә башлана. Ә хуҗабикә үзе бәрәңге утыртуда катнаша алмый: казан астына ягып, икешәр чиләк бәрәңгене әрчеп, эшчеләргә пешерәсе бар. Эшне бетереп, кулларны ишек төбендәге комганнан юган кебек иткәч, өйгә, өстәл янына керер утырабыз. Хуҗабикә агач яки әлүмин табакка пар бөркеп торган ап-ак ярмалы бәрәңге салып, өстәл уртасына китереп утыра. Шул бәрәңге дә, табындагы безнең алабута оны кушып пешерелгән ипи да бик тиз ашала. Сыерлы кешеләр катык та куялар. Май, каймак ише ризыклар үз гаиләләренә дә сирәк эләгә торган еллар.

Бәрәңге күп вакыт майның егермесеннән соң утыртылды. Халык колхоз атларының колхоз эшеннән бушавын көтәргә мәҗбүр иде. Үзенә яки берәр якын күршенә, туганыңа бәрәңге утырткан көнне мәктәпкә, имтихан алды консультацияләренә дә бармый кала идек. Бәрәңгегә багышланган такмаклар да бар иде.

Бәрәңге үстерүчеләргә зур мәшәкать, бер зәхмәт булып колорадо коңгызы чыкты бит әле. Үзем бу афәт чыкканнан соң бәрәңгене алдан ук әрчеп, салкын суга салып торам, аннары суда пешерен, суын түгәм. Безнең татарның бик күп ризыгы бәрәңге кушып әзерләнә бит: бәлеш, аш, кыстыбый, тәкә, өчпочмак...

Элек-электән килгән бер гыйбарә бар. Бәрәңге: «Барганда алып барырмын, кайтырыңа миңа ышанма», – дигән, имеш. Туклыклылыгы шул чама гына, янәсе. Ни генә дисәң дә, бәрәңге – халкыбызның яратып ашала торган ризыгы. Бик вакларын исә тавык-чебешкә, пешереп, төеп, бирәм уч фураж оны кушып болгатып бирдек. Көз, кыш айларында мичкә тәгәрәтү бар иде. Ничек кенә ашасак та, үтәлми иде. Элек тә шулай булган, хәзер дә шулай.

«ВТ» архивыннан

Х.ШӘЙДУЛЛИНА

Әти сабагы

«Нәрсә дә булса эшләр алдыннан бик нык уйланырга кирәк, юкса төзәтеп булмаслык хата ясавың бар», – дип кабатларга ярата иде әтием шуфер (шофер дип укыгыз) Бәдретдин. Унике-унөч яшьләр чамасы булдымы икән – рогатка ясадым. Бик яхшы килеп чыкты. Аңа су буендагы чуерташны куеп ата идем. Берникадәр күнегүләрдән соң, берничә малай урамдагы чыпчыкларны аулрга керештек. Куаклар арасында алар көтүләре белән утыра һәм чыркылдаулары бөтен авылга ишетелә иде. Бернинди куркыныч сизмәгән кошчыклар юл кырыендагы тузанда да рәхәтләнеп коена. Шунда берсенә рогаткадан атып җибәрдем, тимәде. Кошчыклар куркышып, куак башларына тезелешеп утырдылар. Мин кабат рогатканы эшкә җиктем һәм бу юлы бичара чыпчыкның күкрәгенә барып тиде, чыпчык җиргә егылып төште. Кошчыкны канатларыннан эләктердем дә, өйгә алып кайтып, песигә бирергә уйладым. Шулчак каршыма әти килеп чыкты. Ул кошчыкка карады да: «Харап иткәнсең бит, ияшәсен иде әле», – дип башын аска иеп өйгә кереп китте! Мин баскан урынымда калдым, шунда гына үземнең ни кылганымны аңладым. Кулымдагы рогатканы катырак кысып, мич янына киттем. Анда әни, зур мичне ягып, ипи пешерергә әзерләнә иде. Кердем дә кулымдагы рогатканы ялкын эченә томырдым. Шуннан соң рогаткага куз ташлаганым да булмады.

Харис КАМАЛИЕВ

СЕРГЕЙ МИХАЛКОВ БЕЛӘН ОЧРАШУ

Казанның Политик мәгариф йортында 1974 елның 24-25 май көннәрендә Татарстан Язучыларының VIII съезды булды. Әлеге чарага Мәскәүдән атаклы шагыйрь Сергей Михалков белән прозаик Анатолий Алексин килгән иде.

Мин, «Яшь ленинчы» редакциясе заданиесе белән, әлеге шахесләрне табарга тиеш идем. Кунакларның «Казан» кунакханәсендә тукталганнарын белдем дә 25е көнне иртә белән шунда килдем. Алар йокыдан тормаган һәм иртәнге ашны ашарга өлгермәгән иде әле. Ничек тә күрешербез, дип, көтеп утырам шулай. Бераздан болар ашарга кереп китте. Мин исә һаман көтеп утырам. Берзаманны радиодан мөхәррир Эльза Гобәйдуллина (язучы Гариф Гобәй кызы) килде: «Син нишләп утырасың монда?» – ди. Нигә килгәнемне әйтеп тормадым моңа. Кунаклар йокыдан торды, хәзер ашарга кереп китте, дидем. Эльза һаман саен сәгатенә карый. «Они давно туда ушли?» – дип сорый бу миннән. «Байтактан инде», – дим. «Нет, мы же на это время договорились. Я больше ждать не буду!» – диде дә кунакханәдән чыгып китте. Мин исә һаман көтеп утырам. Бик озакка китте бу. Менә бервакыт болар өчәү килеп чыкты. Өченчесе үзебезнең язучы Җәвад Тәрҗеманов иде. Язучылар берлеге кунакларны озатып йөрүне аңа тапшырган, күрәсең. Сергей Михалков:

– Вы не в-в-видели из р-р-радио к-к-кого-нибудь? – дип, тотлыга-тотлыга сорый миннән. Ул шулай гел тотлыгып сөйләшә икән.

– Она уже давно ушла, – дидем.

– Вот д-д-дураки, вот д-д-дураки! – ди Сергей Михалков.

– Я ведь тоже за вами пришла, – дим. Кунакларны үзем белән таныштырам.

– Давайте к нам пойдем, мы тут рядом! – дип, Бауман урамы буйлап, Матбугат йортына алып киттем боларны.

Редакциядә күңелле генә сөйләшеп утырдык. Бик тәмләп чәй эчтек. Бергәләп фотога төштек. Ул фотода, кунак язучылар белән бергә, үзебезнең редакция хезмәткәрләре дә, танылган артистларыбыз да бар. «Әгәр Эльза Гобәйдуллина сабыр итеп көткән булса, безгә Сергей Михалков белән фотога төшү насыйп булмый иде бит», – дип сөендем мин шул чакта.

Саимә ИБРАҺИМОВА

Беренче рәттә уңнан сулга: Саимә Ибраһимова, Сергей Михалков, Җәвад Тәрҗеманов, Анатолий Алексин, Габдулла Шамуков; икенче рәттә уңнан сулга: Зоммер Гыйләҗев, Рәйсә Яхина, Әнәс Сәләхетдинов, Илгизәр Сәмигуллина, Хәмзә Зарипов. 1974 ел. Зоммер Гыйләҗев, Хәмзә Зарипов – «Социалистик Татарстан» газетасы хезмәткәрләре. Язмада искә алганнарның байтагы бакыйлыкка инде. Язма авторы Саимә Ибраһимова да быел бакыйлыкка күчте. Урыннары җәннәттә булсын!

Матак апа

Әнинең туганнары күп булса да, иң аралашып-киңәшләшеп яшәгәннәре сеңлесе Нурания белән абыйсы Шәрифулла иде. Нурания апалар район үзәгендә – Базарлы Матакта гомер иттеләр. Шуңадыр, күрәсең, Нурания апага мин гомер-гомергә «Матак апа» дип дәшә идем.

Мәктәптә укыган елларда, гаиләдә өч малай булгангадыр инде, ипи күп ашала иде. Мин велосипедка утырам да, әни биргән бер сум акчаны алып, еш кына Матакка ипигә китәм. Авыллар арасы – 12 чакрым. Арып-талып Матакка килеп җиткәч, иң элек апаларга керәм. Нурания апа шунда эшли. Ул мине компот, пирожкилар белән сыйлый. Аларның хуш исе, тәме әле дә күңелемне кытыклап тора сыман.

Матак апаларның өйләренә да керәм. Җизни, язгини дядя Петя бик җор телле кеше иде, уен-көлке белән аралаштырып, миңа киңәш-табыш та иткәли, истәлекләр дә сөйли.

...Авылдагы өебез әти исән-имин чагында салынган иде. Ул читтән караганда тәзек-матур кебек. Әмма түбәсе черегән, менә-менә ишелеп төшәм, дип тора. Бу хәлне күргән-белгән дядя Петя, көннәрдән бер көнне өй түбәсен ябу өчен шифер китереп бушатты. Тулы бер машина, абыйларымның шуны берәмтекләп санаганнары, минем ис-акылым китеп карап торганым да хәтердә. Түбәне осталар шифер белән япкач, өебез матур күлмәк кигәндәй булды. Әйе, яхшылык онытылмый шул.

Мин үзем дә мөстәкыйль тормыш юлына баскач, башкаларга ярдәм итү теләге көчәйгәннән-көчәя генә барды. Тормыш иптәшем Әлфия дә: «Яхшылык яхшы булып, начарлык начар булып үзеңә кайтучан ул», – дип искәртеп торды. Әмма кайберәүләр кылган яхшылыкларны аңламаганга сабышып гомер кичерделәр. Аңа карап, бездән бер артык җирләре дә юк иде.

Матак апа да, җизнәбез дядя Петя да тормышның кадерен белеп, мөмкин кадәренчә башкаларга ярдәм кулын сузып яшәделәр. Мин дә кайда гына яшәсәм, эшләсәм дә, Матак апаларны читләтеп үтмәдем. Алардан күч-илһам ала идем. Матакка тукталып, Чуаш урамындагы матур йортка кереп туганнарыбызның хәлен белеп чыгу минем өчен мәртәбә иде.

Хәзер үткәннәрне сагынырга гына калды инде.

Ришат ХАФИЗОВ

КОТЛЫЙБЫЗ!

Татарстан Республикасы мәнфәгатьләрендә күпьеллык нәтиҗәле хезмәте һәм актив иҗтимагый эшчәнлеге өчен Татарстан Республикасында Кеше хокуклары буенча Вәкаләтле вәкил **Сабурская** Сәрия Харис кызы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены** белән бүләкләнде.

***

Республикада миграция сәясәтен гамәлгә ашыруга мөһим өлеш кертүе, күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен Россия Федерациясе Эчке эшләр министрлыгының «Паспорт-виза сервисы» федераль дәүләт унитар предприятиесенең Татарстан Республикасы буенча филиалы директоры **Батьков** Иван Степанович; милли көрәшне популярлаштыруга мөһим өлеш кертүе, актив иҗтимагый эшчәнлеге һәм күпьеллык намуслы хезмәте өчен «Татарстан Республикасы көрәш федерациясе» төбәк иҗтимагый оешмасы башкарма директоры **Хәйруллин** Равил Гарифулла улы; республиканың төзелеш тармагын үстерүдәге казанышлары һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәте өчен «АК БАРС» акционерлык коммерцияче банкы (гавами акционерлык җәмгыяте) идарәсе рәисенең беренче урынбасары, «АК БАРС Девелопмент» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте генераль директоры **Шаһитов** Марат Фоат улы **«Татарстан Республикасы алдындагы казанышлар өчен» ордены медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың дәүләт хакимияте органнарында нәтиҗәле хезмәте өчен Татарстан Республикасы Премьер-министры баш референты **Цесак** Вероника Анатольевна **Татарстан Республикасының «Фидакарь хезмәт өчен» медале** белән бүләкләнде.

***

Татарстан Республикасының социаль-икътисади потенциалын ныгытуга зур өлеш кертүе өчен «Россия экспорт үзәге» акционерлык җәмгыятенең Төркия Республикасындагы вәкиле **Гыйматдинов** Радик Рөстәм улы **«Татарстан Автономияле Совет Социалистик Республикасы төзелүгә 100 ел» медале** белән бүләкләнде.

***

Республиканың нефть сәнәгатен үстерүгә өлеш кертүләре һәм күпьеллык нәтиҗәле хезмәтләре өчен В.Д.Шашин исемендәге «Татнефть» гавами акционерлык җәмгыяте Скважиналарны җир астында төзекләндерү идарәсенең җитештерүгә хезмәт күрсәтү цехы элеткт һәм газ белән эретеп ябыштыручысы **Әхмәдиев** Азат Миннитаһир улына; «Татнефть-АЗС Центр» җаваплылыгы чикләнгән җәмгыяте Казан филиалының автомобильләргә ягулык салу станцияләрен эксплуатацияләү цехы 258, 183 номерлы ягулык салу станцияләре мастерлары **Шакирова** Елена Юрьевнага **«Татарстан Республикасының атказанган нефтьчесе»** дигән мактаулы исем бирелде.

Белдерү

Извещение о необходимости согласования проекта межевания

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:380, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, территория паевого фонда СХПК «Кама». Заказчиком кадастровых работ является Абдуллин Рафис Габдрафикович (422640, РТ, Рыбно-Слободский район, с. Большая Елга, ул. Школьная, д. 45, тел.: 89393356137). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

Извещение о необходимости согласования проекта межевания

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:327, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, территория паевого фонда СХК «Маяк». Заказчиком кадастровых работ является Залялов Алмаз Марсович (422650, РТ, Рыбно-Слободский район, пгт Рыбная Слобода, ул. Некрасова, д. 33, тел.: 89274129400). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

Извещение о необходимости согласования проекта межевания

Кадастровым инженером Самоховым Александром Сергеевичем (420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005; 6238322@mail.ru; тел.: 89178883476, № квалификационного аттестата 16-12-546) подготовлен проект межевания земельного участка, выделяемого в счет земельных долей из земельного участка с кадастровым номером 16:34:000000:422, расположенного по адресу: Республика Татарстан, Рыбно-Слободский муниципальный район, территория паевого фонда СХК «Уныш». Заказчиком кадастровых работ является Залялов Алмаз Марсович (422650, РТ, Рыбно-Слободский район, пгт Рыбная Слобода, ул. Некрасова, д. 33, тел.: 89274129400). С проектом межевания можно ознакомиться с понедельника по пятницу с 9.00 до 17.00 ч. по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005, тел.: 89178883476. При проведении согласования местоположения границ при себе необходимо иметь документ, удостоверяющий личность, а также документы о правах на земельный участок. Обоснованные возражения и предложения по доработке проекта межевания принимаются в письменном виде в течение тридцати дней со дня опубликования данного извещения по адресу: 420133, РТ, г. Казань, ул. Академика Лаврентьева, д. 11, пом. 1005.

Сорау – җавап

Илдар Мөхәммәтҗанов

«Авырмассың», димиләр, «яшәрсең», диләр

Сер түгел, вакцина ясаткан кешеләр дә чирләргә мөмкин. Берәү дә прививканы сырхаудан чын панацея дип атамый. Вакцина ясаткан кеше, чирләсә дә, аны җиңел кичерә, хастаханә бусагасын таптамый. Прививкасыз кешедән өстенлеге дә әнә шул инде. Татарстан Сәламәтлек саклау министрлыгының штаттан тыш баш терапевты Диана ГАБДЕЛГАНИЕВА вакцина һәм чир йоктыруга бәйле төп сорауларга җавап бирде.

1 Коронавируска каршы тору өчен, организмдагы антитәнчекләр күләме күпме булырга тиеш?

Бу сорауга гомум кабул ителгән җавап юк. Мин, антитәнчекләр дәрәҗәсенә карамастан, ярты ел саен ревакцинация үтәргә (яңадан вакцина ясатырга. – **Ред.**) киңәш итәм. Бөтендөнья сәламәтлек саклау оешмасы да шушы фикердә тора.

2 Прививкадан соң да кеше авырырга мөмкин. Бу ни өчен шулай?

Моны кеше организмында чиргә каршы иммунитет формалашып өлгермәгәнлек белән аңлатырга була. Гадәттә, иммунитет вакцина дозалары арасындагы вакыт аралыгында яисә икенче доза алганнан соң барлыкка килә. Икенче дозадан соң тулы 21 көн узарга тиеш. Прививканың беренчесен алганнан соң организм зәгыйфь була. Шуңа да кеше күп булган урыннарда йөрмәскә, битлек кияргә кирәк. Вакцина курсы тәмамлангач та, берничә көн узгач чирләү очраклары була. Россия вакциналарының нәтиҗәлелеге югары булуга карамастан, кайберәүләрдә антитәнчекләр бөтенләй барлыкка килми. Андыйларга башка препарат белән прививка ясарга тәкъдим ителә. Прививкалы кеше, авырса да, аны гадәти салкын тию кебек кенә кичерә.

3 Ревакцинация өчен нинди вакцина ясатырга киңәш ителә?

Кабат вакцина ясату өчен нинди препарат сайлавыгыз беренче тапкыр ясатканда кайсын куллануыгызга бәйле. «Спутник V» һәм «Спутник Лайт» – моның өчен менә дигән препаратлар. Беренче тапкыр вакцина ясатканда «ЭпиВакКорона», «КовиВак» кадаткан булсагыз, «Спутник V» вакцинасыннан файдаланырга була. «Спутник V» ясатучылар өчен «Спутник Лайт» туры килә.

4 Коронавирус белән авырган кешегә кайчан урамга чыгарга ярый соң?

Коронавирус белән авырган вакытта урамга чыгу чирли башлаганнан соң җиде көн узгач кына мөмкин. Урамда йөрү, һава сулау амбулатор дәвалану алган очракта рөхсәт ителә, тик моның шарты бар. Үпкәләр зарарланмаган булырга тиеш. Сырхауларга башка кешеләр белән күрешү тыела!

Әгәр дә кешедә үпкә ялкынсынуының җиңел формасы ачыкланса, актив хәрәкәтләр инфекция үрчүенә һәм таралуына этәрәчәк. Шуңа күрә сырхауларга кирәгеннән артык йөрмәскә, ятып тору киңәш ителә. Хәл кергәч, берәр атнадан соң урамга чыгарга, йөри башларга мөмкин.

5 Нинди чирләрдән вакцина юк?

Хәзергә кадәр кешелекне С гепатиты һәм ВИЧ-инфекциядән сакларлык вакциналар уйлап табылмаган. Шул ук вакытта башка авырулардан прививка ясату бик мөһим. Вакциналардан баш тарту кешелек дөньясын куркыныч астына куяр иде. Кыска вакыт эчендә коронавируска каршы вакцина уйлап табу – галимнәребезнең зур алгарышы. Без инфекцияләрнең гомер озынлыгын кыскартуы турында, яшьли балалар үлеме турында оныттык. Кешелек бу хакта вакциналар булганга гына оныта алды. Бу шулай дәвам итәчәк дип, кешеләргә тынычланырга мөмкинлек бирелде. Әмма без яши торган мохит яңадан-яңа сюрпризлар китереп чыгара.

Чулпан ГАРИФУЛЛИНА


«ВТ» КАЙДА – ШУНДА ФАЙДА
РЕКЛАМА БҮЛЕГЕ
(843) 222-09-65, 222-09-70.
E-mail: vtreklama@mail.ru

90 яшьлек Рәвгать Сәлахов:

«Язмышка үпкәләргә ярамый»

Чирмешән районының Лашман авылында яшәүче 90 яшьлек Рәвгать ага Сәлахов план кормыйча йокларга ятмый. Гомер буе күнегелгән гадәтен бернәрсә дә үзгәртә алмый. Бакчаны казып бетерәсе бар, кишерләрне җыеп аласы... Ул шулай итеп хәтереннән башкарасы көзге эшләрне барлый. Бар дөньясыннан нур, яктылык бөркелеп торса да, күңелендәгесе сыкрап чишмә булып агарлык. Тик ул зарланмый...

Илдар Мөхәммәтҗанов

Балачагындагы гыйбрәтле язмышы, өйләнгәч, тагын кабатланган аның. Иң гаҗәбе, серле саннар да бер тирәдә чуалган. Үткәннәренә карата үпкәләре онытылган инде. Бүген ул – кадерле әти, бабай.

– Без биш бала идек. Әти сугышка киткәч, берничә айдан алтынчыбыз туды. Шулай итеп, алты малай булдык. Иң олысы – мин. Сугышта яраланган әтигә тугыз ай буе Омскида госпитальдә ятарга туры килә. Дәвалангач, кабат фронтка китә. Яу кырында мәңгелеккә ятып кала. Үлгән дигән хәбәрен ишетү бик авыр булды. Әни 35 яшьтә тол калды. Үпкә чире белән авыргач, озак яши алмады, 40 яшьтә бакыйлыкка күчте. Миңа – 16, ә иң кечебез Рашатка 5 яшь иде. Хәзерге вакытта икәү генә калдык. Әхсән энемә 80 яшь, ул Чаллыда яши, – дип сөйли Рәвгать ага.

Әниләре үлгәч, биш бертуганын тәрбияләү аның җилкәсенә кала. Ризыгын да табарга, барысын да тәртиптә тотарга кирәк. Күп тә үтми, авыл советы рәисе белән районның хәрби комиссары Сәлаховларның алтысын да Суворов училищесына җибәрергә дип килә. Без риза түгел дип, барысы да мич артына кереп качалар. Башка бу хакта сүз чыкмый. Әле ярый күршедә яшәүче туганнары Нурзидә әби була. Авыр чакларда ярдәм итә, кунарга да кергәли. Яшәү кыенлашкач, энекәше Әсгатьне Таҗикстанга туганнары янына җибәреп карыйлар. Әмма ул озак тормый, җимеш тутырган биштәрен асып, өенә кайтып төшә. Артык кашык кирәк булмагандыр, күрәсең. Ә җимеш тәме авызда озак саклана. Бишенче энекәшен колхозда токарь булып эшләүче Рәхмәтулла абый уллыкка алырга теләгән. 8 яшьлек балага тегеләр әти-әни дип әйтергә кушкан, ә ул каршы булган. Шулай итеп, кире өенә әйләнеп кайткан. Туганлык җепләре нык булса да, тормыш авырлыклары кайберләренең юлларын икегә аера. Районнан белгечләр килеп, дүртенче, бишенче туганнары Әхсән белән Әхтәмне балалар йортына озата. Анда 7 сыйныфка кадәр укып, икесе дә Казандагы һөнәр училищесында токарь белгечлеген алалар. Соңыннан өйләнеп, үз тормышларын коралар.

– Малайлар шук була. Биш энекәшегезне ничек тыңлата алдыгыз? – дип сорыйм Әсгать агадан.

– Салам түбәле йортта яшәдек. Кыш көне салкын була иде. Әни үлгәч, сыерны бетердек. Үгез җигеп, печән, салам ташыдык. Эш куша идем дә эшкә китә идем. Үземне җитди тоттым, ачуланган чаклар да булгалады. Мәсхүт су ташып, ашарга пешерә иде. Без бу эшкә кысылмадык. Каралты-кура, абзардагысын тәртиптә тоттык. Ашарга бер әйбер юк. 1942дән 1952 елга кадәр ипине бөтенләй күрмәдек. Бәрәңге ашадык. Мин армиягә киткәндә, күршедән ике пот арыш бурычка алып, энекәшләргә биреп калдырдым. Кайткач, түләдем. Әсгать белән Мәсхүт комбайн ярдәмчесе булып эшләде, аннан икмәк бирә башладылар. Берсе дә тәртипсез булмады, кеше әйберенә тимәде, йөзгә кызыллык китермәде. Кыйнап акыл кертеп булмый, яхшылап аңлатырга кирәк, – ди ул.

Армиягә барып кайткач, Рәвгать Разиягә өйләнеп, зур итеп йорт сала. 17 ел матур гына яшәгәннән соң, хатыны яман шештән үлеп китә. Бу вакытта Разия әнисе кебек 40 яшьтә була. Олысы Рузалиягә – 16, кечесе Ринатка – 5 яшь. Кадрия, Фәридә, Фәрхәт, Тәлгать... Балалар арасында аерма – икешәр яшь. Өч кыз, өч малай. Тол калган иргә балаларына әти генә түгел, әни дә булырга туры килә. Кабат өйләнеп караса да, никахы уңышлы булмый. Күпбалалы ир белән яшәргә сабырлыклары җитмәгәндер, күрәсең. Балалары яхшы укый аның. Ике кызы укытучылыкка укый. Кызлары энекәшләрен карарга, ашарга пешерергә, өйдәгесен тәртиптә тотарга булыша. Гаилә башлыгын авылда алтын куллы балта остасы дип йөртәләр. Мәктәптә укытучы булып эшләүче кызы – Кадриясе, көн саен килеп, әтисенә булышып тора. Әле менә сарымсак утыртып киткән. Чаллыда яшәүче кызлары кайтып хәлен белешеп тора. Уллары да ярдәменнән ташламыйлар.

Рәвгать абый 60 яшендә дин юлына басып, Коръән кушканча яши башлый. Мәчеткә дә йөргәли. Кирәк йомышына мотоблок белән баргалый. Эшләмичә торырга яратмый. Көрәк белән бәрәңгесен кызый, бакчасын китмәнли, ишегалдын себерә. Чисталык, тәртипне яратам, ди. Газеталар, дини китаплар укырга да вакыт таба.

– Аллаһы Тәгалә биргән язмыштан качарга, зарланырга ярамый. Үзем теләгән түгел бит ул, минем кебекләр күп. Дөрес, үсмер чакта, әти-әни назына сусагач, эш кушучы булмагач, ник безгә мондый ятимлекне бирдең, дип елаган чаклар да булды. Үткәннәрне искә төшереп, бүген дә күзгә яшьләр килә әле, – ди бабакай. – Тәртипле булдым, эчмәдем, тартмадым. Авырлыкларны эш белән җиңдем. Һәрвакыт үземне кулда тотарга тырыштым. Тормыш авыр, эш күп, дип кул селтәсәң, барысы да өеләчәк. Шуңа күрә яшәргә көч табарга, кеше булып калырга кирәк. Суыткыч ризык белән тулган. Пенсияне вакытында бирәләр. Тормышыма шөкер, зарланыр урын юк.

Сәрия МИФТАХОВА

Уйлы күңел уйлана

АВЫЛ ДА ҮЗГӘРӘ

Түрең нинди?

Хәреф хатасы түгел, «ә» хәрефе дә төшеп калмаган. Бүген сүзем гади бер өй түре турында. Һәм аның турында гына да түгел.

Күз алдыгызга элекке гади бер авыл өе килдеме? Шәһәр фатирыннан аермалы буларак, бу өйләрдә ишек каты, түр башы, түр өй була иде. Хәзер инде күпләр заманча өйләрдә, элеккеләренә янкормалар өсти-өсти бөтен кеше аларны зурайтып бетерде. Авыл яшьләре бүген «ишек каты», «өй түре» кебек сүзләрне кулланмый. Әмма әле өлкәннәр сөйләмендә алар яши, шулай ук бала чакта күңеленә сеңеп калган безнең буын кешеләре өчен бу сүзләр зур мәгънәгә ия. Һәм туры мәгънәдә генә дә түгел. Әйтик, бер чорда, авыл өйләренең яртысын тутырган зур мичләр патша булып утыра һәм аның арты өйдәге бөтен кирәксез әйберне чит-ят кеше күзләреннән яшерә иде: күмер чиләге, кибәргә дип кертелгән утын, калдык-постык ризыкларны, табак-савыт юа торган суларны сала торган маллар чиләге (безнең якта шулай дип йөртелә иде ул), сөлге-тастымаллары белән юынгыч... Үткән гасырның туксанынчы елларында (кайдадыр иртәрәк, кайдадыр соңрак) авылларга табигый газ килде, бөтен кеше янкорма итеп котельныйлар салды. Газ миче, плитәләр шунда күчте. Зур мичләр сүтелде. Гомер буе мич арты, аралык булып йөргән урыннар түр башына әйләнде дә куйды. Бу хакта бер уйланып, кешеләр, яшәешебез мисалына күчереп, бу тормышта түр башы булуың да, мич артына әйләнүең дә бик тиз икән дип язган идем.

Хәзер инде авылларда да ишек каты – прихожий, түр өйләр зал дип йөртелә. Соңгы вакытта бу нисбәттән дә гади, әмма күңелгә тиярлек бер хикмәт ачылды бит әле. Егерме ике елдан артык йөри алмаучы әниебез башта түр өйдә – залда ятты. Өйгә кергән бөтен кеше – бакчадан, укудан кайткан балалар да, эштән кайтуга үзебез дә, хәл белергә килгән туганнар, күрше-күлән дә туры шунда – залга керә иде. Безнең дә бөтен тормыш шунда үтә, барыбыз шунда җыелыша идек. Безнең өчен иң рәхәт урын да шул иде.

Илдар Мөхәммәтҗанов

Моннан унбиш еллап элек өй артына буйдан-буйга янкорма, җылы бәдрәф, өйдән генә йөри торган мунча эшләдек. Шулар янәшәсендә әнигә бер бүлмә дә калды. Барысы да әнигә уңайлырак, бәдрәф белән мунча якынрак булсын өчен эшләнсә дә, ияләнгән урыным дип, ике еллап анда күченмәде әни. «Урам буе бит, һич югы үткән-йөргән кешеләрне карап утырырсың», – дигәч, ризалашты һәм бик тиз ияләнде дә. Әни белән без дә шул якка күчендек. Хәзер инде өйгә кергән һәр кеше иң элек шунда – мунча һәм бәдрәф якын гына булган, арткы яктагы бүлмәгә ашыга. Залга – кайчандыр иң җылы, иң матур бүлмә булып тоелган якка борылып караучы да юк... Әни кайда – җыелу урыны шунда... Өйнең түр башы да, иң матур, җанга иң рәхәт урыны да шул...

Спидометр

– Бер көн балалар хәл белергә килде дә: «Әни, әти, яшегез бара, бераз сәламәтлегегезне ныгыту турында уйлагыз инде, иртәләрен бераз хәрәкәтләнегез, физкультура ясагыз, әнә күпләр скандинавиячә йөрергә чыга, кичләрен сез дә һава сулап кайтыгыз», – дип, икебезгә дә махсус таяклар калдырып киттеләр. Безгә боларның кирәге юк, без гел хәрәкәттә, дим. Әле бит без яшь пенсионерлар, мал-туар, кош-корт асрыйбыз. Иртәле-кичле шуларны карау үзе фәләнчә километр җәяүләп йөрүгә тиң, дим. Ышанмыйлар, көләләр. Шулайдыр инде, өй белән абзар-кура арасында йөреп, километрлар үтмисездер, ди болар. Мин дә бит төшеп калганнардан түгел, кулда заманча телефон. Бер көнне иртән тордым да телефонны көйләп куйдым. Абзар белән өй арасында керә-чыга йөреп, су эчертеп, ашатып, асларын җыештырып кына да иртә белән ике километрдан артык юл үткән булып чыктым. Тиз генә экрандагы нәтиҗәне балаларга җибәрдем. Менә, мин әйтәм, ышанмаган буласыз... – дип сөйли район үзәгендә яшәүче бер танышым. – Әле көне буе йөргәнне исәпләсәң, күпмегә җыйналыр иде икән...

Без, авыл кешеләре, үзара, бигрәк тә җәен үз хуҗалыгыбызда эшләп, көненә ничә чакрым тәпилибез икән, аякта спидометр булса, исәпләр иде дип, шаярып еш сөйләшәбез. Бар бит ул иренмәгән, чын хикмәт иясе булган кешеләр. Әнә исәпләп караучысы да табылган. Әле ул юл иртәнгесе генә...

Гөлсинә ХӘБИБУЛЛИНА

Баш мөхәррир – САБИРОВА Гөлнара Ильяс кызы

Газетаны оештыручылар:
ТАТАРСТАН ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ, МИНИСТРЛАР КАБИНЕТЫ, РЕДАКЦИЯНЕҢ ХЕЗМӘТ КОЛЛЕКТИВЫ

Газета Татарстан Республикасы Информация һәм матбугат министрлыгында 1995 елның 21 июнендә теркәлгән.

Теркәү таныклыгының номеры – 430.
Газета матбугат чараларының үзәк каталогына кертелгән.

Тираж – 7405 данә
Гомуми тираж – 17243 данә

Газетага сертификат бирелде

Заказ 343

РЕДАКЦИЯ ҺӘМ НӘШЕР АДРЕСЫ

420097, Казан, Академия ур., 2 й.
«Ватаным Татарстан» газетасы редакциясе.

www.vatantat.ru

info@vatantat.ru, vatantat@list.ru, vtreklama@mail.ru

89179270040

Индекс П2409 (гадәти сан – атнага дүрт тапкыр чыга)
П2448 (гадәти сан, пенсионерлар өчен)
П2449 (гадәти сан, оешмалар өчен)
П2435 (җомга саны)

ТЕЛЕФОННАР

222-09-70 – кабул итү бүлмәсе
222-09-73, 222-09-67 – баш мөхәррир урынбасарлары
222-09-68 – авыл хуҗалыгы
222-09-67 – фән һәм мәгариф
222-09-64 – әдәбият, сәясәт һәм дин
222-09-66 – информация, спорт, тәрҗемә, оператор
222-09-67 – хатлар һәм социаль мәсьәләләр
222-09-65 – реклама бүлеге
222-09-72 – бухгалтерия
222-09-73 – компьютер үзәге
221-18-99 – газета килмәсә яки соңарып килсә

Оригинал макет **Jahat™** программалар пакеты ярдәмендә әзерләнде. Мәкалә авторларының фикерләре редакция фикере белән туры килмәскә мөмкин. Хатлар, кульязмалар, рәсемнәр рецензияләнми һәм кире кайтарылмый.
R тамгасы куелган язмалар реклама буларак тәкъдим ителә.
N тамгасы куелган язмалар килешү нигезендә басыла.

Күчереп бастыру өчен редакциядән язмача рөхсәт алу шарт.
График буенча бу санга 20 сәгатьтә кул куелырга тиеш.
Кул куелды – 20 сәгатьтә.

Ваклап сату бәясе килешү буенча.

Газета «ТАТМЕДИА» АҖ филиалы «Идел-Пресс» полиграфия-нәшрият комплексында басылып чыкты **(420066, Казан шәһәре, Декабристлар ур., 2й.).**

16+